**Республика Татарстан**
**Совет Поручиковского**
**сельского поселения Заинского**
**муниципального района**

ул.Новая, д. 13 с.Поручиково,
Заинский район, (индекс)423520
тел. 3 70 49

**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Поручик авыл җирлеге**
**Советы**

Новая урамы, 13нче йорт,
Поручик авылы, Зәй районы,
(индекс) 423520 тел. 3 70 49

Телефон, факс 3-70-49. Электронный адрес: Por.Zai@tatar.ru, сайт: www.http://zainsk.tatarstan.ru/poruchikovskoe.htm

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**13.11.2018 ел** **№01**

**«2019 елга һәм 2020 - 2021 еллар план чорына Зәй муниципаль районының Поручик авыл җирлеге бюджеты турында» Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлеге Советы карар проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Бюджет кодексына, Татарстан Республикасы Бюджет кодексына, Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлеге Уставына һәм Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлегендә ачык тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә таянып,

## карар бирәм:

1. «2019 елга һәм 2020 - 2021 еллар план чорына Зәй муниципаль районының Поручик авыл җирлеге бюджеты турында» Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлеге Советы карар проекты буенча ачык тыңлауларны 2018 елның 20 ноябрендә иртәнге сәгать 11.00 дә түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Поручик авылы, Горбунов урамы, 2 а йорты.

2. Поручик авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Хаджаева Ильмира Ильсуровнага:

- ачык тыңлаулар үткәрүне оештырырга;
- әлеге карарны, ачык тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре буенча беркетмәне Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырырга, шулай ук җирлекнең мәгълүмати стендларына эләргә;
- «2019 елга һәм 2020 - 2021 еллар план чорына Зәй муниципаль районының Поручик авыл җирлеге бюджеты турында» Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлеге Советы карар проектын Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлегенең рәсми сайтында, авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Татарстан

Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга (кушымта).

3. «2019 елга һәм 2020 - 2021 еллар план чорына Зәй муниципаль районының Поручик авыл җирлеге бюджеты турында» Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлеге Советы карар проекты буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр язмача формада түбәндәге адреска җибәрелә: 423537, Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Поручик авылы, Горбунов урамы, 2 а йорты (конвертта «бюджет турында фикер алышу» тамгасы белән).

4. Законлылык, регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә, утырышта яңгыраган һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлеге Советы каравына кертергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Авыл җирлеге башлыгы** **П.С. Уразайкин**

Кушымта

**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районының**
**Поручик авыл җирлеге Советы**

**КАРАР ПРОЕКТЫ**

**2019 елга һәм 2020 - 2021 еллар**
**план чорына Зәй муниципаль**
**районының Поручик авыл**
**җирлеге бюджеты турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлеге Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ

1 статья 1

1. 2019 елга Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлеге бюджетының фаразланыла торган керем күләмен 4852,8 мең сум күләмендә;

2) Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 4852,8 мең сум күләмендә;

3) Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлеге бюджет кытлыгын 0 мең сум.

2. 2020 елга һәм 2021 елга Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлеге бюджетының 2020 елга фаразланыла торган керем күләмен 4893,2 мең сум һәм 2021 елга 4928,2 мең сум күләмендә;

2) Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлеге бюджетының 2020 елга чыгымнары күләмен 4893,2 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнарны 123,3 мең сум күләмендә һәм 2021 елга 4928,2 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнарны 469,5 мең сум күләмендә;

3) Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлегенең 2020 елга бюджет кытлыгын 0 мең сум һәм 2021 елга 0 мең сум итеп.

3. Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлегенең 2019 елга һәм 2020 - 2021 еллар план чорына бюджет кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

Статья 2

1. Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлегенең 2020 елның 1 гыйнварына муниципаль эчке бурычының югары чиген 0 мең сум, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча эчке бурычның югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга.

2. Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлегенең 2021 елның 1 гыйнварына муниципаль эчке бурычының югары чиген 0 мең сум, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча эчке бурычның югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга.

3. Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлегенең 2022 елның 1 гыйнварына муниципаль эчке бурычының югары чиген 0 мең сум, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча эчке бурычның югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга.

4. Зәй муниципаль районы Поручик авыл жирлегенең муниципаль бурычның иң чик күләмен түбәндәгечә билгеләргә:
- 2019 елга 0 мең сум;
- 2020 елга-0 мең сум;
- 2021 елга 0 мең сум күләмендә.

3 статья

Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлеге бюджетында 2019 елга, 2020 - 2021 еллар план чорына Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләмнәрен әлеге карарга 2 кушымта нигезендә исәпкә алырга.

4 статья

1. Зәй муниципаль районы Поручик авыл жирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 3 кушымта нигезендә расларга.
2. Зәй муниципаль районы Поручик авыл жирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 4 кушымта нигезендә расларга.

5 статья

1. 2019 елга һәм 2020 - 2021 еллар план чорына Зәй муниципаль районының Поручик авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарга 5 кушымта нигезендә расларга.
2. 2019 елга һәм 2020 - 2021 еллар план чорына Зәй муниципаль районының Поручик авыл җирлеге бюджет ассигнованиеләрен бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге карарга 6 кушымта нигезендә расларга.
3. Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлеге бюджетының халык алдында норматив йөкләмәләрне үтәү өчен бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2019 елга 0 мең сум, 2020 елга 0 мең сум, 2021 елга 0 мең сум күләмендә расларга.

6 статья

1. Вәкаләтләрнең бер өлешен тормышка ашыру буенча төзелгән килешүләр нигезендә Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлеге бюджетыннан Зәй муниципаль районы бюджетына җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләре күләмен түбәндәгечә расларга: Поручик авыл җирлегендә яшәүчеләрне мәдәният учреждениеләре хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыру буенча 2019 елга – 2665,32 мең сум, 2020 елга – 2665,3 мең сум, 2021 елга 2665,3 мең сум күләмендә.
2. 2019-2021 елларда әлеге статьяда каралган бюджетара трансфертларны Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлеге бюджетыннан Зәй муниципаль районы бюджетына күчерү ай саен тигез өлешләр белән гамәлгә ашырыла, дип билгеләргә.

7 статья

Зәй муниципаль районының Поручик авыл җирлеге бюджетында Зәй муниципаль районы бюджетыннан жирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияне 2019 елда 2409,4 мең сум, 2020 елда 2449,5 мең сум, 2021 елда 2481,4 мең сум күләмендә исәпкә алырга.

8 статья

Зәй муниципаль районының Поручик авыл җирлеге бюджетында Зәй муниципаль районы бюджетыннан хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга алына торган субвенцияләр күләмнәрен исәпкә алырга: 2019 елда - 86,4 мең сум, 2020 елда - 86,7 мең сум, 2021 елда 89,8 мең сум күләмендә.

9 статья

1. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.10 статьясы нигезендә, Зәй муниципаль районының Поручик авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле бюджетара субсидияләрне 2019 елда елга 29,5 мең сум, 2020 елга 61,9 мең сум, 2021 елга 62,7 мең сум күләмендә расларга.

2. Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлеге бюджетыннан Зәй муниципаль районы бюджетына бюджера субсидияләрне күчерү ай саен, тигез өлешләр белән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

10 статья

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары 2019 елга 2020-2021 еллар план чорында муниципаль хезмәткәрләр, бюджет өлкәсе учреждениеләре һәм оешмалары хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

11 статья

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешү нигезендә Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыралар.

12 статья

Муниципаль контрактларның шартлары нигезендә 2018 елда түләнергә тиешле товарлар китерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү өчен Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлеге исеменнән төзелгән муниципаль контрактлар өчен түләүгә файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре суммасыннан артмый торган күләмдә Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлеге бюджетының 2019 елның 1 гыйнварына калган акчалары 2019 елда, Зәй муниципаль районының Поручик авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан тиешле карар кабул ителгән очракта, күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

13 статья

Әлеге карарны җирле массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://zainsk.tatarstan.ru.

14 статья

Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **П.С. Уразайкин**